ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлегенең Александровка торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

18 ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елнын 06 октябрендәгы № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлегенең Александровка авылында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Александровка авыл җирлеге Александровка авылы территориясендә яшәүче инвалидлардан, 80 яшькә җиткән өлкән кешеләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, ашыгыч хәрби хезмәт, контракт буенча хәрби хезмәт һәм мобилизация буенча хәрби хезмәт узучылардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Александровка т..п. урамнарында яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы (лампаларны, энергияне сак тоту яктырткычларын, электр товарларын сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын агымдагы ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү);

2) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Александровка т.п. Нефтьчеләр урамында янгын сүндерү гидрантын сатып алу һәм урнаштыру);

3) Александровка т.п. гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын (янәшәсендәге территорияләрдәге үләннәрне чабып тоту, ЯММ, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

4) жирле әһәмияттәге юлларны кышкы чорда кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

5) су башняларын, скважиналарны су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын ремонтлау (су саклау зонасын төзекләндерү, төзелеш материаллары сатып алу, коймалар урнаштыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү.

6) Александровка т.п. эчендәге эшләрне ремонтлау, Айзатулов урамы юлына вак таш җәю.

3. Әлеге карарны Александровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында ( http:// sarmanovo. tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Александровка авыл җирлеге башлыгы
гражданнар җыенында рәислек итүче И.Ф.Вафин